РУКОВОДИТЕЛЬ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО
КОМИТЕТА АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ЖИТӘКЧЕСЕ

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-44, E-mail: aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

«01» 11 2019 № ПР-256

**Актаныш муниципаль районы муниципаль берәмлегенең "2020 елга балаларга өстәмә белем бирүче туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге мәгариф оешмаларының һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күппрофильле мәгариф оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында"**

«Мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ санлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы балаларга өстәмә белем бирүче туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни мәгариф учреждениеләрен финанслау нормативларын исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында" 2009 ел, 31 декабрь, 939 нчы санлы карары, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының, «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы белән

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2020 елга расларга:

Балаларга өстәмә белем бирүче туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге мәгариф оешмаларында һәм Актаныш муниципаль районы балаларга өстәмә белем бирүче күп профильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнар.

балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында, туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге өстәмә белем бирү оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирү күппрофильле мәгариф оешмаларында 0,5 күләмендә өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнарга карата төзәтү коэффициенты.

2. Актаныш муниципаль районы муниципаль берәмлегенең финанс-бюджет палатасына тәэмин итәргә:

әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә балаларга өстәмә белем бирү буенча мәгариф оешмаларын финанслау;

әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары чоры дәвамында, хезмәт законнарында һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла торган өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакын индексацияләү белән бер үк вакытта яңадан карау.

3. Әлеге закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2020 елның 1 нче гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмати рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында түбәндәге адрес буенча: http://aktanysh.tatarstan.ru. урнаштырылырга тиеш.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Л. Ф. Нурлыева

Актаныш муниципаль районы
муниципаль берәмлеге
башкарма комитеты
җитәкчесенен
«01» 11 2019 № ПР-256
карары белән расланган

**Актаныш муниципаль районының балаларга өстәмә белем бирүче туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге мәгариф оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күппрофильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыру турында НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР**

| Өстәмә белем бирү программасының юнәлеше | Территориаль урнашу | Норматив чыгымнар, елга 1 укучыга сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | беренче уку елы | икенче ел уку | өченче һәм аннан соңгы уку еллары |
| Сәнгать-эстетик | авыл җирлеге | 5 970 | 11 055 | 13 266 |
| Физкультура-спорт | авыл җирлеге | 5 868 | 10 867 | 13 041 |
| Техник иҗат | авыл җирлеге | 6 273 | 11 617 | 13 940 |
| Туризм һәм туган якны өйрәнү | авыл җирлеге | 6 071 | 11 242 | 13 940 |
| Экологик-биологик | авыл җирлеге | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Хәрби-патриотик | авыл җирлеге | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Социаль-педагогик | авыл җирлеге | 5 666 | 10 493 | 12 591 |
| Социаль-икътисадый | авыл җирлеге | 5 666 | 10 493 | 12 591 |
| Табигый-фәнни | авыл җирлеге | 6 071 | 11 242 | 13 491 |